КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 август г.Казань № 674

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу турында» 2006 ел, 26 май, 310 нчы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм аларны бетерү максатларында хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен, хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алу нәтиҗәсендә гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннардан эшләнгән продуктлар һәм чималны эшкәртү һәм саклау предприятиеләрендә дәүләт ветеринария күзәтчелеге турында нигезләмәне һәм хайваннарның аеруча куркыныч авыруларында хайваннарны һәм терлекчелек продукциясен алу тәртибе хакында аңлатманы раслау турында» 2002 ел, 29 гыйнвар, 38 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрүнең кирәклеге турында» 2018 ел, 31 июль карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы вирусы чыганаклары барлыкка килүен кисәтү һәм юкка чыгару максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2018 ел, 21 июль, ПУ-518 нче, «Татарстан Республикасының аерым территорияләрендә йогышлылыгы югары булган кош гриппы белән чирләү һәм аның таралу куркынычы янау белән бәйле рәвештә, аларның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында» 2018 ел, 28 июль, ПУ-543 нче указларының 1 пункты һәм 3 пунктның «а» пунктчасы белән билгеләнгән территорияләрдә хайваннарны алуны һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрергә.

2. Карарга теркәлгән хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрү буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны алу һәм терлекчелек продуктларын алуны үткәрү буенча махсус комиссиягә билгеләнгән тәртиптә әлеге карарның 1 пунктында каралган чараларны башкаруны оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин